**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 01.04.2022** **№ 390**

**Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында**

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 29 апреленә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә, атап әйткәндә – Зарипов Марат Хатыпович милкендәге 1107 квадрат метр мәйданлы, 16:16:090101:696 кадастр номерлы җир кишәрлеген «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» төреннән «кибет» төренә, 14 сәгать 00 минутта, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз ав., Ленин ур., 28 й., Дөбъяз авыл җирлеге администрациясе бинасында.

2. Әлеге карарны һәм гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны Дөбъяз авыл җирлеге территориясендәге махсус җиһазландырылган стендларда, Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә урнашкан ТР Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда 2022 елның 4 апреленнән 2022 елның 29 апреленә кадәр чорда һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә (халыкка җиткерергә).

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне язма рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау станциясе т/юл.п., Кооператив ур., 5 йорт адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2022 елның 4 апреленнән 2022 елның 28 апреленә кадәр чорда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм

торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдинов тарафыннан һәм шулай ук 2022 елның 29 апрелендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә. Тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерергә.

5. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә һәм аны Дөбъяз авыл җирлеге территориясендәге, Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда махсус җиһазландырылган стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ф. Шәйдуллин